| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШАРЛИАРЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
18 декабрь 2025 ел

КАРАР
№ 40

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрен акчалата карау турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.11.2025 № 994 карары нигезендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында «Җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында», районның Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Башкарма комитетының 10.08.2018 ел, № 9 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең акчалата тәэмин ителеше турында» нигезләмәгә (01.10.2020 ел, № 12, 17.06.2024 №10, 01.11.2024 №18, 30.04.2025 № 18 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-карарның 1 нче кушымтаның 2 пунктында «15389» санын «16928» саннарына алмаштырырга;

2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә әлеге карарны игълан итәргә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шәрләрәмә авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе Н.Н.Хуҗина